**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

КАРАР

«27» ноябрь 2018 ел. Яр Чаллы № 5720

«Тукай муниципаль районы муниципаль
бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә
белем алучы укучыларның кайнар туклануын оештыру турында»

Укучыларны балансны кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, аларның сәламәтлеген саклау, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.4.5.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 10 сентябрендәге 2019 номерлы «Айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең банка төрләре турында»гы, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы аерым категорияләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру максатында,

**Карар бирәм:**

1. 2018 елның сентябреннән расларга:

1.1. Белем бирү учреждениеләре укучылары өчен (1-11 сыйныфлар) кайнар аш оештырган өчен ата-аналардан аена 738 сум күләмендә түләү каралган.

1.2. 1-11 сыйныф укучылары өчен көнгә кайнар туклану бәясе гомуми белем бирү учреждениеләрендә 37 сум 40 тиен күләмен тәшкил итә;

1.3. Айлык акчалата түләүләр бәясе:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2018 елның 10 октябрендәге 2019 номерлы карары нигезендә уку чорында бер укучыга көненә 7 сум 40 тиен.

1.4. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен ата-аналар түләве суммасы 30 сум 00 тиен.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларны 2018 - 2019 уку елында кайнар тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).

3. «Социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларына мохтаҗ белем алучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру комиссиясе составын расларга. (2 нче кушымта)

4.Укучыларның түбәндәге категорияләрен ата-аналар взносларын түләүдән азат итәргә:

4.1. Татарстан Республикасында җан башына керем уртача яшәү минимумыннан түбәнрәк булган очракта, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы булган гаиләләр өчен карала.

4.2. Тукай муниципаль районының идарә тармагы социаль-тернәкләндерү консилиумы карары нигезендә аз тәэмин ителгән гаиләләрдән, гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе үтенече буенча, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр өчен (алга таба-СОП), аз керемле гаиләләр өчен карала.

5. Гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә каралган акчаларны үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

6. Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

6.1. 2019 елдан муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга.

6.2. 2019 елдан дүрт һәм аннан да күбрәк балалы булган, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында һәм аз керемле гаиләләрдән

кайнар азык-төлек оештыру буенча МСРК карары нигезендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдәге укучыларга кайнар аш ашатуны оештырырга.

6.3.Санитар-гигиена нормаларының СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

6.4. Ай саен «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесендә туклануны оештыру буенча хисап бирергә (3 нче кушымта, 4 нче кушымта).

7. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе:

7.1. Гомуми белем бирү учреждениеләренә продуктларның өзлексез килүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

7.2. «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерүне тәэмин итәргә.

8. 2019 елның гыйнварыннан «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җаваплы, аңа социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән укучы кайнар аш бирүне оештыру турында мәгълүмат бирүне, бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба-ЕГИССО) куллану юлы белән, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, җиткерүне тәэмин итә.

9. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының күп балалы һәм аз керемле гаиләләреннән гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2018 елның 10 сентябрендәге 2019 номерлы күрсәтмәсе үз көчен югалткан дип санау хакында» 2008 ел, 11 май, 316 нчы карары.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.Г. Авзалов